**СОВЕТ**
**Кичкетанского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кичкетан авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.08.2018 с. Кичкетан № 44-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлегенең җәмәгать тыңлаулары, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Положениене раслау турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасы информациясен 15 май 2018 ел № 02-01-18-2018 карап, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законына 6 октябрь 2003 ел №131-ФЗ, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” гы Законына 28 июль 2004 ел №45-ЗРТ, Әгерҗе муниципаль районының “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Кушымтага туры китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлегенең җәмәгать тыңлауларын, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Положениене расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге җәмәгать тыңлаулары турындагы Положение турында”гы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы карарын 02.02.2009 № 2-2.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына http//agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карарны үтәүгә контрольне Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советының финанс-бюджет, социаль законлылылык һәм хокук тәртибе даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе З.Р. Нуриев

Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы карары белән РАСЛАНГАН

Җәмәгать тыңлауларын, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында ПОЛОЖЕНИЕ

## 1 маддә. Гомуми положениелар

1.1 Әлеге Положение "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон 06.10.2003 131-ФЗ, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы Законы 28 июль 2004 ел № 45-ЗРТ, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп эшләнде һәм Әгерҗе муниципаль районы "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тыңлауларын һәм фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2 Әлеге Положениенең максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

**Җәмәгать тыңлаулары** – авыл җирлеге халкының җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияте булган мәсьәләләр буенча муниципаль актлар кабул итү процессында катнашуга хокукын тормышка ашыру формасы;

**Җәмәгать фикер алышулары** – җәмәгать контроле максатларында иҗтимагый мәсьәләләр, дәүләт власте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль оешмалары һәм федераль законнар нигезендә аерым җәмәгать вәкаләтләрен башкаручы башка органнар һәм оешмалар карарлары проектлары буенча фикер алышу. Фикер алышуларда күрсәтелгән органнар һәм оешмаларның вәкаләтле затлары, гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең катнашуы мәҗбүри.

**Җәмәгать тыңлауларын оештыру** – тыңлауларның вакытын һәм үткәрү урынын хәбәр итүгә, муниципаль хокук акты проекты белән таныштыруга, җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләрен игълан итүгә юнәлтелгән эшчәнлек;

**Җәмәгать фикер алышуларын оештыру** – җәмәгать фикер алышуларының башлануын хәбәр итүгә, проект белән таныштыруга, җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәләрен игълан итүгә һәм халыкның җәмәгать фикер алышуларында катнашуын тәэмин итү өчен башка оештыру чараларына юнәлтелгән эшчәнлек;

**Җәмәгать тыңлауларында һәм фикер алышуларында катнашучылар** – төрле профессиональ һәм социаль төркемнәр вәкилләре, җирле үзидарә органнары вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый берләшмәләр, җәмәгать тыңлауларында һәм фикер алышуларында катнашырга теләк белдергән башка затлар;

**Җәмәгать тыңлаулары һәм фикер алышулары инициаторы** – аларны үткәрү турында белдергән физик һәм юридик зат, муниципаль берәмлек органы яки муниципаль берәмлек башлыгы;

**Оештыру комитеты** – җәмәгать тыңлауларын һәм фикер алышуларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру эшләрен башкару өчен махсус формалаштырылган коллегиаль орган;

**Җәмәгать тыңлаулары һәм фикер алышуларының йомгаклау документы** – җәмәгать тыңлаулары һәм фикер алышуларының беркетмәсе, аларның нәтиҗәләре буенча заключение.

## 2 маддә. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү максатлары һәм принциплары

Төп максатлары:

2.1. авыл җирлеге халкы катнашында муниципаль норматив хокук актлары проектлары буенча фикер алышу;

2.2. җәмәгать тыңлауларына чыгарылган җирле әһәмияте булган мәсьәләләр буенча җәмәгать фикерләрен ачыклау һәм исәпкә алу;

2.3. власть органнары һәм авыл җирлеге халкының диалог механизмнарын үстерү;

2.4. җирле мөһим мәсьәләләрнең альтернатив чишелешен эзләү;

2.5. фикер алыша торган проблемалар буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрне эшләү.

Җәмәгать тыңлауларын әзерләү, үткәрү һәм нәтиҗәләрен билгеләү ачыклык, иреклелек принциплары нигезендә башкарыла.

## 3 маддә. Җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләр

Җәмәгать тыңлауларына чыгарылырга тиеш:

3.1. муниципаль берәмлек уставы проекты, уставка кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр турында муниципаль норматив хокук акты проекты. Бу муниципаль берәмлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе положениеләре, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнарына тәңгәлләштереп үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә кагылмый;

3.2. җирле бюджет һәм аның үтәлеше турында отчет проекты;

3.3. муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты:

3.4. муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, үзгәртеп кору өчен гражданнар җыеннарында тавыш бирү юлы белән халыкның ризалыгын алу таләп итүдән тыш;

3.5. генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне мижалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, әлеге расланган документларга үзгәрешләр кертүгә кагылган проектлар, җир участоклары һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителү төренә рөхсәт бирү турында карар проекты, капиталь төзелеш объектларына

реконструкция, җирдән һәм төзелешләрдән файдалануның расланмаган кагыйдәләре булмаганда алардан файдалануның бер төреннән икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре.

**4 маддә. Җәмәгать тыңлауларын билгеләү тәртибе**

4.1. Җәмәгать тыңлаулары авыл җирлеге халкы, “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы йә “Кичкетан авыл җирлеге” Башлыгы инициативасы белән үткәрелә.

4.2. Халыктан чыккан җәмәгать тыңлауларын “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы билгели. “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгыннан чыккан җәмәгать тыңлауларын “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Башлыгы билгели.

4.3. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы карар авыл җирлеге органы йә вазифаи зат тарафыннан муниципаль норматив хокук акты каралганга кадәр 20 көн алдан кабул ителә.

4.4. Карарда күрсәтелә:

- җәмәгать тыңлауларының темасы;
- җәмәгать тыңлауларының инициаторы;
- җәмәгать тыңлауларының датасы, башлану һәм тәгәлләнү вакыты;
- үткәрү урыны;
- җәмәгать тыңлауларында каралачак мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм кимчелекләрне тәкъдим итү вакыты һәм урыны, тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты һәм урыны.

4.5. Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында карар аны кабул иткән көненнән көченә керә. Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турындагы карар, муниципаль норматив хокук акты проекты, “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларына, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырыла, шулай ук җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның әлеге информациягә керүне тәэмин итә торган ысуллар кулланыла.

**5 маддә. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе**

5.1. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү өчен “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы депутатларыннан һәм “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты вәкилләреннән торган 3 кешелек оештыру комитеты формалаштырыла.

5.2. Җәмәгать тыңлаулары халык тарафыннан билгеләнгән булса, инициатив төркем вәкилләре оештыру комитеты утырышларында катнаша ала. Бу утырышларда җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнаша ала.

5.3. Җәмәгать тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге казнасы чараларына башкарыла. Оештыру комитеты

әгъзалары җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү буенча җәмәгать башлангычында эшлиләр.

5.4. Оештыру комитеты үз рамкаларында:

- җәмәгать тыңлауларының көн тәртибен әзерли;

-җирле үзидарә органнарыннан җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләргә кагылышлы мәгълүмат һәм документлар сорый;

- җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны терки, гражданнардан җәмәгать тыңлаулары рамкасында чыгыш ясау өчен гаризалар кабул итә;

- гражданнардан җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча кергән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрне "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрне таныштыру өчен Әгерҗе муниципаль районы сайтына урнаштыра;

- Оештыру комитеты адресына кергән тәкъдимнәрдән, кемнән кергәнен күрсәтеп, бердәм документ формалаштыра;

- җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат чаралары, интернет челтәре аша гражданнарга игълан итә;

- җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирүен оештыра;

- җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләрен урнаштыра;

- йомгаклау документы проектын әзерли, аны районның мәгълүмат стендларына, район сайтына урнаштыра;

- җәмәгать тыңлауларында кабул ителгән рекомендация һәм тәкъдимнәрне формалаштыра, аларны "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендларына һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыра;

– җәмәгать тыңлауларында кабул ителгән рекомендация һәм тәкъдимнәрне формалаштырып, җәмәгать тыңлауларын билгеләгән җирле үзидарә органына тапшыра.

5.5. Әлеге документларны рәсми рәвештә җирле үзидарә органына тапшырганнан соң оештыру комитетының вәкаләтләре туктатыла.

5.6. Җәмәгать тыңлаулары транспорт белән килерлек бинада үткәрелә. Оештыру комитеты тыңлаулар үткәрелә торган бинага керү өчен киртәләр булмауны оештыра.

5.7. Җәмәгать тыңлаулары башланырга утыз минут кала анда катнашучыларны теркәү башлана. Анда аның ФИО, эш урыны, адресы языла.

5.8. Җәмәгать тыңлауларында оештыру комитеты рәисе рәислек итә. Ул тыңлауларны ача, көн тәртибен игълан итә, үзе, секретарь белән таныштыра, тыңлаулар үткәрүнең инициаторын күрсәтә. Оештыру комитеты секретаре җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен алып бара.

5.9. Рәислек итүче сүзне инициаторлар вәкиленә бирә.

5.10. Ул чыгыш ясаганнан соң фикер алышулар башлана.Чыгыш ясау өчен сүз гаризалар керү чираты буенча бирелә. Чыгыш ясау вакытын рәислек итүче билгели.

5.11. Рәислек итүче теләсә кайчан, вакытын әйтеп, тәнәфес игълан итә ала.

5.12. Тыңлауларда катнашучылар үзләренең тәкъдимнәрен кире ала яки башкаларның тәкъдимнәренә кушыла алалар.

5.13. Фикер алышулардагы тәкъдимнәр буенча бердәм тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр исемлеге төзелә. Йомгаклау документына авторлар тарафыннан кире алынмаган барлык тәкъдимнәр кертелә. Рәислек итүче катнашучылар инициативасы белән йомгаклау документына барлык яки өлешчә тәкъдимнәрне кертергә хокуклы.

5.14. Йомгаклау документын төзеп бетергәннән соң рәислек итүче җирле әһәмияте булган мәсәләләр буенча карарның йомгаклау вариантын тавыш бирүгә куя. Карар ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Һәр катнашучы бер тавышка ия. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә.

5.15. Тыңлаучылар тарафыннан бөтен тәкъдим ителгән карар вариантлары кире кагылса, тыңлаулар инициаторы әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, йомгаклау карарын яңадан эшлиләр. Инициатор теге яки бу мәсьәләне караудан алырга тәкъдим кертә ала. Кире эшләнгән карар җәмәгать тыңлауларына чыгарыла. Өстәмә җәмәгать тыңлауларының саны чикләнмәгән.

5.16. Оештыру комитеты 7 көн эчендә җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләрен бердәм документка формалаштыра һәм аның күчермәсен җирле үзидарә органына тапшыра. Шулай ук Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтына һәм "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендларына бастыру (халыкка җиткерү) өчен тапшыра.

**6 маддә. Җәмәгать тыңлауларының йомгаклары**

6.1. Йомгаклау документы "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы өчен тәкъдим итү характерына ия.

6.2. Йомгаклау документы җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре тыңлаулар инициаторына һәм авыл җирлеге халкына "Кичкетан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендларына һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтына кую юлы белән җиткерелергә тиеш.

**7. маддә. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җәмәгать тыңлауларын, җәмәгать фикер алышуларын оештыруның һәм үткәрүнең үзенчәлекләре**

7.1. Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре расланмаган булса, генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне мижалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, әлеге документларга үзгәрешләр кертү проектлары, җир участогыннан яки капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрләренә рөхсәт бирү турындагы карар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең чикләнгән параметрларыннан читкә тайпылуга ризалык бирү турындагы карар проектларына, капиталь төзелеш объектларына реконструкция үткәрү буенча җәмәгать фикер алышулары яки җәмәгать тыңлаулары үткәрелә. Аларны оештыру һәм үткүрү Авыл җирлеге Уставы һәм (йә) әлеге Положение белән билгеләнелә.

7.2. Җир участокларын яки капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә, рөхсәт ителгән төзелешнең чикләнгән параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре, капиталь төзелеш объектларына реконструкциягә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча фикер алышулар һәм тыңлаулар белән бәйле чыгымнарны бу мәсьәләләр буенча кызыксынучы физик яки юридик зат күтәрә.

7.3. Җәмәгать фикер алышуларында һәм тыңлауларында катнашучылар:

- генераль планнар, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру, территорияне мижалау проекты, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, әлеге документларга үзгәрешләр кертү проектлары буенча – әлеге территориядә даими яшәүчеләр, әлеге территория чикләрендә җир участоклары һәм анда капиталь төзелеш объектлары булган гражданнар;

- җир участокларына һәм капиталь төзелеш объектларына шартлы рөхсәт төренә рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларына реконструкция буенча – әлеге территория чикләрендә даими яшәүче, әлеге территория чикләрендә җир участоклары, капиталь төзелеш объектлары урнашкан гражданнар.

7.4. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

7.4.1. җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итү;

7.4.2. проектны һәм башка информацион материалларны “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендлары, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру, экспозицияне яки экспозиция проектын ачу;

7.4.3. экспозиция яки экспозиция проектын үткәрү;

7.4.4. җәмәгать фикер алышуларының беркетмәсен әзерләү һәм оформить итү;

7.4.5. җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәләрен әзерләү һәм бастыру.

7.5. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

7.5.1. җәмәгать тыңлауларының башлануы турында хәбәр итү;

7.5.2. проектны һәм аңа кагылышлы материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм экспозицияне яки шундый проект экспозициясен ачу;

7.5.3. җәмәгать тыңлауларында каралачак экспозицияне яки экспозиция проектын үткәрү;

7.5.4. җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышларын үткәрү;

7.5.5. җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен әзерләү һәм формалаштыру;

7.5.6. җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре турында заключение әзерләү һәм аны бастыру.

7.6. Җәмәгать тыңлаулары һәм фикер алышулары башлану турында хәбәр итү түбәндәгеләрдән тора:

7.6.1. проект турында мәгълүмат һәм аңа кагылышлы мәгълүмати материаллар исемлеге;

7.6.2. җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм срогы турында мәгълүмат;

7.6.3. экспозиция яки экспозиция проектын ачу урыны, датасы турында, экспозицияне карау көннәре һәм сәгатьләре турында мәгълүмат;

7.6.4. җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлауларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр кертү тәртибе, срогы турында мәгълүмат;

7.6.5. проектлар һәм информацион материаллар урнашачак рәсми сайт турында мәгълүмат бирү;

7.6.6. җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелыш үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат.

7.7. Җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлаулары башлану турында хәбәр итү:

7.7.1. проектны рәсми сайтта урнаштырганга кадәр җиде көннән дә соңга калмый мәгълүмат чараларында;

7.7.2. муниципаль берәмлек территориясендәге мәгълүмат стендларында, башка муниципаль хокук актлары эленә торган махсус билгеләнгән урыннарда, гражданнар күп җыела торган урыннарда, җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлаулары узачак территорияләр чикләрендә.

7.8. Проектны һәм информацион материалларны урнаштыруның бөтен чорында экспозиция яки шундый проект экспозициясе үткәрелә. Экспозиция эшләү дәверендә анда катнашучылар өчен консультацияләр, проект турында мәгълүмат оештырылырга тиеш. Консультацияне “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белгечләре үткәрә.

7.9. Әлеге проектны, информацион материалларны караганда, экспозиция үткәргәндә фикер алышуларда, тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәрен кертергә хокуклы:

7.9.1. рәсми сайт яки мәгълүмат системасы аша;

7.9.2. җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышларында язмача яки телдән;

7.9.3. фикер алышуларны һәм тыңлауларны оештыручылар адресына язмача;

7.9.4. экспозициядә катнашучыларны исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язу юлы белән.

7.10. Әлеге мадданең 8.9 частенә тәңгәл китереп кертелгән тәкъдимнәр теркәлергә тиеш, аларны фикер алышулар һәм тыңлауларны оештыручының да каравы мәҗбүри, әлеге мадданең 7.14 частендә каралган очрактан тыш.

7.11. Җәмәгать фикер алышуларында һәм тыңлауларында катнашучылар үзләре турында белешмә (ФИО, туган көне, яшәү урыны) тапшыралар – физик затлар өчен. Юридик затлар өчен – исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашкан урыны, адресы, бу белешмәләрне раслаучы документлар. Җир участокларына хокукы булганнар һәм анда капиталь төзелеш объекты булганнар әлеге участоклар, объектлар турында Бердәм дәүләт реестрыннан документлар тапшыралар.

7.12. Әлеге мадданең 7.11 частендә күрсәтелгән документларны – физик затлар ФИО, туган елы, урнашкан урыны, адресны тапшырмыйлар; юридик затлар төп дәүләт теркәү номерын, урнашкан урыны, адресы турында документ тапшырмыйлар. Моның өчен рәсми сайтта яки информацион системада тәкъдимнәр урнаштырылырга тиеш.

7.13. Җәмәгать фикер алышуларында һәм тыңлауларында катнашучыларның персональ мәгълүматлары “Персональ мәгълүматлар турында”гы Федераль закон (27 июль 2006 ел, 152-ФЗ) кысаларында эшкәртелә.

7.14. Әгәр фикер алышуларда һәм тыңлауларда катнашучылар дөрес булмаган мәгълүмат тапшыра икән, аның тәкъдимнәре каралмый.

7.15. Фикер алышуларны һәм тыңлауларны оештыручыларга проектларга керү өчен бертигез хокук бирелә.

7.16. Рәсми сайт һәм информацион система түбәндәге мөмкинлекләрне тәэмин итәргә тиеш:

7.16.1. рәсми сайт һәм информацион системага алар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрнең тулылыгы һәм дөреслеген тикшерү;

7.16.2. җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре, аларда катнашучылар саны турында мәгълүмат бирү.

7.17. Җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлауларын оештыручы беркетмә әзерли һәм формалаштыра, андатүбәндәгеләр күрсәтелә:

7.17.1. җәмәгать фикер алышуларын һәм җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен формалаштыру датасы;

7.17.2. оештыручы турында мәгълүмат;

7.17.3. җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлаулары башлану турында басылган хәбәрнең басылу датасы, басылу чыганагы.

7.17.4. тәкъдимнәр кабул ителү срогы турында белешмә, фикер алышулар, тыңлаулар үткәрелү урыны турында мәгълүмат;

7.17.5. барлык кергән тәкъдимнәр икегә бүленә: - фикер алышулар һәм тыңлаулар үткәрелгән территориядә яшәүчеләрдән һәм башка катнашучылардан.

7.18. Беркетмәгә катнашучылар исемлеге беркетелә. Физик затлар өчен үзләре турында белешмә (ФИО, туган елы, яшәү урыны). Юридик затлар өчен төп дәүләт теркәү номеры, урнашкан урыны, адресы.

7.19. Фикер алышуларда, тыңлауларда катнашып, аның тәкъдимнәре каралган булса, ул катнашучы беркетмәдән өземтә алырга хокуклы.

7.20. Беркетмә нигезендә фикер алышуларны оештыручы җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлаулары турында заключение әзерли.

7.21.Заключениедә күрсәтелә:

7.21.1. заключение формалаштыруның датасы;

7.21.2. проектның исеме, фикер алышуларда, тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмә,;

7.21.3. беркетмә реквизитлары;

7.21.4. барлык кертелгән тәкъдимнәрнең эчтәлеге, бер төрле тәкъдимнәр булса, аларны берләштерү мөмкин.

7.21.5. фикер алышу, тыңлауларны оештыручының кертелгән тәкъдимнәр турында максатка яраклымы-юкмы икәнлеген дәлилләгән рекомендациясе.

7.22. Җәмәгать фикер алышулары һәм тыңлаулары нәтиҗәләре турында заключение рәсми сайтта һәм башка информацион системаларда урнаштырыла.

7.23. Территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча фикер алышулар һәм тыңлаулар үткәрү вакыты ул башлану турында бастырылганнан соң бер айдан ким һәм өч айдан артык булмаска тиеш.

**8 маддә. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү процедурасын бозган өчен вазифаи затларның җаваплылыгы**

8.1. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибен бозган вазифаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

8.2. Җәмәгать тыңлаулары законда каралган тәртипне, шул исәптән әлеге актны бозып үткәрелгән, ул гражданнарның үз фикерләрен әйтүне чикләгән яки мәхрүм иткән булса, бу тыңлаулар үткәрелмәгән булып санала. Бу очракта тыңлаулар яңадан билгеләнелә.